КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 22 апрель г.Казань № 481

Зәй муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктына, «Татарстан Республикасы Җир кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында» 2026 елның 19 февралендәге 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Зәй муниципаль районында урнашкан 0,5099 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеген 16:19:060104:508 кадастр номеры белән ритуаль эшчәнлек объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин